СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
2015 елның 10 ноябре

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 25

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында

«Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе П. Н. Сергеевның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын расларга (карта һәм текст нигезләмәсе кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны аның кушымталары белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (ФГИС ТП) әлеге карарны кабул иткән көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**